РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
АБДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Школьная ул., д.1, с.Абди, 422084
тел. (факс): (84360) 5-54-16,
E-mail: Abd.Tul@tatar.ru



ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘБДЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ**

Мәктәп ур., 1 нчы йорт, Әбде авылы, 422084
тел. (факс): (84360) 5-54-16,
E-mail: Abd.Tul@tatar.ru

ОКПО 93053638 ОГРН 1061675010187 ИНН/КПП 1619004394/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№15** **29 сентября 2021 года**

**Әбде авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы «Салым түләүчеләргә һәм салым агентларына салымнар һәм җыемнар турында муниципаль хокукый актларны куллану мәсьәләләре буенча язмача аңлатмалар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында административ регламентны раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 509-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 3 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Әбде авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Әбде авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы «Салым түләүчеләргә һәм салым агентларына салымнар һәм җыемнар турында муниципаль хокукый актларны куллану мәсьәләләре буенча язмача аңлатмалар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында административ регламентны раслау хакында» карарына (26 март 2020 № 7 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Салым түләүчеләргә һәм салым агентларына салымнар һәм җыемнар турында муниципаль хокукый актларны куллану мәсьәләләре буенча язмача аңлатмалар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында Административ регламентына:

А) II бүлек:

– 2.6.6 пунктын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«2.6.6. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүчедән таләп итәргә хокуклы түгел:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә